КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь | г.Казань | № 1203

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2020 ел, 17 март, 192 нче, 2020 ел, 14 июль, 590 нчы, 2020 ел, 5 август, 656 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фонды 1 381,294 мең сумлык 58 берәмлек күләмендә билгеләргә.»;


әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәдә 3.2 пунктның унтугызынчы - егерме беренче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республика-сының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы структурасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 12 июль, 566 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 август, 653 нче, 2020 ел, 30 июль, 638 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы структурасына, аны яңа редакциядә (discarded) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 12 июль, 566 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы структурасы




_______________